# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 апреля 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1; 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 57 (часть I); 2022, № 34 (часть I), № 96 (часть I); 2023, № 27 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте 3 статьи 4 слова «и деловыми» исключить;

2) в статье 10:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Для замещения должности государственной службы требуется соответствие квалификационным требованиям к уровню профессионального образования, стажу государственной службы или работы по специальности, направлению подготовки, профессиональному уровню, а также при наличии соответствующего решения представителя нанимателя – к специальности, направлению подготовки (к укрупненным группам специальностей и направлений подготовки), к квалификации, полученной по результатам освоения дополнительной профессиональной программы профессиональной переподготовки.»;

б) часть 9 изложить в следующей редакции:

«9. Квалификационные требования к профессиональному уровню устанавливаются в зависимости от категории и группы должностей государственной службы, области и вида профессиональной служебной деятельности государственного служащего его должностным регламентом. Должностным регламентом государственного служащего (далее – должностной регламент) могут также предусматриваться квалификационные требования к специальности, направлению подготовки (к укрупненным группам специальностей и направлений подготовки), к квалификации, полученной по результатам освоения дополнительной профессиональной программы профессиональной переподготовки, которые необходимы для замещения должности государственной службы.»;

в) дополнить частями 12 и 13 следующего содержания:

«12. Проверка соответствия гражданина, претендующего на замещение должности государственной службы, или государственного служащего квалификационным требованиям для замещения должности государственной службы осуществляется подразделением государственного органа по вопросам государственной службы и кадров (далее также – кадровая служба государственного органа), если иное не установлено Федеральным законом.

13. В целях проверки соответствия гражданина, претендующего на замещение должности государственной службы, или государственного служащего квалификационным требованиям к профессиональному уровню кадровой службой государственного органа осуществляется оценка профессионального уровня указанного гражданина или государственного служащего для замещения должности государственной службы. Оценка профессионального уровня осуществляется с использованием не противоречащих федеральным законам и другим нормативным правовым актам Российской Федерации методов оценки с участием подразделения государственного органа, в котором учреждена соответствующая должность, и органа по управлению государственной службой. По решению руководителя государственного органа или уполномоченного им лица к оценке профессионального уровня могут привлекаться научные, образовательные и другие организации, специализирующиеся в соответствующих областях и видах профессиональной служебной деятельности государственных служащих или в вопросах кадровых технологий и государственной службы, а также их представители.»;

3) в части 4 статьи $11^1$ второе предложение исключить;

4) в статье $11^2$:

а) часть 5 признать утратившей силу;

б) часть 17 изложить в следующей редакции:

«17. Решение о присвоении государственному служащему классного чина, за исключением случаев, указанных в части 16 настоящей статьи, должно быть принято в срок не позднее одного месяца со дня внесения представления о

присвоении классного чина со всеми необходимыми документами в орган или должностному лицу, уполномоченным присваивать классные чины.»;

в) в части 18 слова «без проведения квалификационного экзамена» исключить;

5) в пункте 6 части 1 статьи 15 слова «уровень квалификации» заменить словами «профессиональный уровень»;

6) в статье 20:

а) в части 1 слова «и являющимся составной частью административного регламента государственного органа» исключить;

б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Положения должностного регламента учитываются при проведении конкурса на замещение вакантной должности государственной службы и включение в кадровый резерв государственного органа, а также при назначении на должность государственной службы без проведения конкурса, аттестации, планировании профессиональной служебной деятельности и профессионального развития государственного служащего.»;

в) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. Исполнение государственным служащим должностного регламента учитывается при его участии в конкурсе на замещение вакантной должности государственной службы или включении в кадровый резерв государственного органа, а также при назначении на должность государственной службы без проведения конкурса, оценке его профессиональной служебной деятельности при проведении аттестации либо поощрении.»;

7) часть 1 статьи 21 дополнить предложением следующего содержания: «Аттестация включает в себя оценку профессиональной служебной деятельности государственного служащего и оценку его профессионального уровня.»;

8) статью 22 признать утратившей силу;

9) в статье 34:

а) в части 1:

в пункте 1 слова «и деловых качеств» исключить;

в пункте 2 слово «мастерства» заменить словом «уровня»;

б) в пункте 5 части 2 слова «или квалификационного экзамена» исключить;

10) часть 1 статьи 36 изложить в следующей редакции:

«1. Профессиональное развитие государственного служащего направлено на поддержание и повышение государственным служащим профессионального уровня и включает в себя дополнительное профессиональное образование и иные мероприятия по профессиональному развитию.»;

11) в части 1 статьи 41:

а) пункт 1 дополнить словами «, включая поиск и привлечение кадров, оценку профессионального уровня претендентов на замещение должностей государственной службы, проверку соответствия квалификационным требованиям для замещения должностей государственной службы»;

б) пункт 11 признать утратившим силу.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
03 мая 2023 года
№ 37-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 пунктында «һәм эшлекле» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, дәүләт хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, профессиональ дәрәҗәгә, шулай ук яллаучы вәкиленең тиешле карары булган очракта – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәренә), яңадан һөнәри әзерләүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.»;

б) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Профессиональ дәрәҗәгә карата квалификация таләпләре дәүләт хезмәте вазыйфаларының категориясенә һәм төркеменә, дәүләт хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентында билгеләнә. Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентында (алга таба – вазыйфаи регламент) шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәренә), яңадан һөнәри әзерләүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 өлешләр өстәргә:

«12. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданны яисә дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү, Федераль законда башкасы каралмаган булса, дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсе (алга таба шулай ук – дәүләт органының кадрлар хезмәте) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданны яисә дәүләт хезмәткәрен профессиональ дәрәҗәгә карата квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү максатларында дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан әлеге гражданның яисә дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен профессиональ дәрәҗәсен бәяләү гамәлгә ашырыла. Профессиональ дәрәҗәне бәяләү, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән бәяләү алымнарын кулланып, дәүләт органының тиешле вазыйфа булдырылган бүлекчәсе һәм дәүләт хезмәте белән идарә итү органы катнашында гамәлгә ашырыла. Дәүләт органы җитәкчесе яисә ул вәкаләт тапшырган зат карары нигезендә профессиональ дәрәҗәне бәяләүгә дәүләт хезмәткәрләренең профессиональ хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә яисә кадрлар технологияләре һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча махсуслаша торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, шулай ук аларның вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин.»;

3) $11^1$ статьяның 4 өлешендә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4) $11^2$ статьяда:

а) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 17 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Дәүләт хезмәткәренә классы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 16 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, классы чиннар бирергә вәкаләтле органга яисә вазыйфаи затка барлык кирәкле документлар белән бергә классы чин бирү турында тәкъдим кертелгән көннән бер айдан да соң булмаган срокта кабул ителергә тиеш.»;

в) 18 өлештә «квалификация имтиханын уздырмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 15 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктта «квалификация дәрәҗәсен» сүзләрен «профессиональ дәрәҗәне» сүзләренә алмаштырырга;

6) 20 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм дәүләт органы административ регламентының бер өлеше булып торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Вазыйфаи регламент нигезләмәләре дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәргәндә, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына конкурс үткәрмичә билгеләп куйганда, аттестация үткәргәндә, дәүләт хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеген һәм аны профессиональ үстерүне планлаштырганда исәпкә алына.»;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентны үтәве ул дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашканда яисә дәүләт органының кадрлар резервына кертелгәндә, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына конкурс үткәрмичә билгеләп куелганда, аттестация үткәргәндә йә бүләкләгәндә аның профессиональ хезмәт эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алына.»;

7) 21 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Аттестация дәүләт хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеген бәяләүне һәм аның профессиональ дәрәҗәсен бәяләүне үз эченә ала.»;

8) 22 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 34 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктта «һәм эшлекклелек сыйфатларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «һөнәри осталыгын» сүзләрен «профессиональ дәрәҗәсен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 5 пунктында «яисә белгечлек имтиханы» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 36 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше дәүләт хезмәткәренең профессиональ дәрәҗәсен тәэмин итүгә һәм арттыруга юнәлдерелгән, һәм аңа өстәмә һөнәри белем алу һәм һөнәри үсеш буенча башка чаралар керә.»;

11) 41 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктта «составын» сүзеннән соң «, кадрларны эзләүне һәм җәлеп итүне, дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен бәяләүне, дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүне тикшерүне дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

б) 11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 37-ТРЗ